ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.02.2022 Мөслим № 58

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (2019 елның 6 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы ред.) һәм әлеге законның кушымтасында бирелгән Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү методикасы, «Торак урыны мәйданының исәпкә алу нормасы һәм дәүләт торак программалары буенча торак урын бирү нормасы турында» 2006 елның 8 сентябрендәге 157 номерлы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 статьяларына һәм «Татарстан Республикасының бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлыгының «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 20 номерлы хатына таянып, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРДЕ:**

1. 2022 елга гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен муниципаль торак фондының торак урыннарын социаль наем шартнамәләре буенча сатып алуның базар хакының түбәндәге чик күрсәткечләрен билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге чик күләмен билгеләргә:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен – 828 069,00 сум;

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 1 053 022,00 сум;

1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 1 355 022,00 сум;

1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 1 806 696,00 сум;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 2 258 370,00 сум;

1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен – 2 710 044,00 сум;

1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 3 161 718,00 сум;

1.1.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 3 613 392,00 сум.

1.2. Исәпләүләр буенча гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткече күләме (1нче кушымта) тәшкил итә:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен: 14 862,78 сум;

1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен: 9 458,14 сум – гаиләнең һәр әгъзасына;

1.2.3. Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен: 8 106,97 сум – гаиләнең һәр әгъзасына.

2. Торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдаланырга.

3. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Р.В. Мухсиновка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфасын башкаручы** **М.Р. Бадретдинова**

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның _______________
____ номерлы карарына
кушымта

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен исәпләп чыгару.**

Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең чик күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 – (1 + ПС) – КП ) / (0,3 х РС), биредә:

ПД – гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урын алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең чик күрсәткече;

СЖ – социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алу өчен базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ= НП х РС х РЦ, биредә:

НП – гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС – гаилә әгъзалары саны;

РЦ – Татарстан Республикасында торак урын сатып алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмый торган торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе;

ПС – бер айга кредит буенча процент ставкасы (унлы вакланма), (2022 елның гыйнварына Россия Федерациясе Үзәк банкының ипотека буенча торак кредиты буенча уртача исәпләнгән ставкасы  елга 7,59%, ягъни 7,59/100/12=0,006 – айга);

КП – кредитның барлык вакыты буенча кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны) (2021 елның гыйнварына Россия Федерациясе Үзәк банкының ипотека буенча торак кредиты буенча уртача исәпләнгән вакыты 254,2 ай);

РС – гаилә әгъзалары саны;

0,7 – кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы;

0,3 – кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы

«Татарстан Республикасының бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлыгының «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 20 номерлы хаты нигезендә 2022 елда Мөслим муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе 25 093,00 сум тәшкил итә.

Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечен исәпләү:

| НП - торак урының нормасы (кв. м) | СЖ - торак урын сатып алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ х НП) (сум) | РС - гаилә әгъзалары саны (кеше) | РЦ - торак урынның 1 квадрат метрының базар бәясе (сум) | ПС - Кредит буенча айлык процент ставкасы, (уртача еллык – 7,59%) (7,59/100/12) | КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | Кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы | кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма керемe белән чагыштырмасы. | ПД - керемнең чик күләме (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 8 | 9 | 9 |
| 33 | 828069,00 | 1 | 21861,00 | 0,006 | 254,2 | 0,7 | 0,3 | 14862,78 |
| 42 | 1053906,00 | 2 | 21861,00 | 0,006 | 254,2 | 0,7 | 0,6 | 9458,14 |
| 54 | 1355022,00 | 3 | 21861,00 | 0,006 | 254,2 | 0,7 | 0,9 | 8106,97 |
| 72 | 1806696,00 | 4 | 21861,00 | 0,006 | 254,2 | 0,7 | 1,2 | 8106,97 |
| 90 | 2258370,00 | 5 | 21861,00 | 0,006 | 254,2 | 0,7 | 1,5 | 8106,97 |
| 108 | 2710044,00 | 6 | 21861,00 | 0,006 | 254,2 | 0,7 | 1,8 | 8106,97 |
| 126 | 3161718,00 | 7 | 21861,00 | 0,006 | 254,2 | 0,7 | 2,1 | 8106,97 |
| 144 | 3613392,00 | 8 | 21861,00 | 0,006 | 254,2 | 0,7 | 2,4 | 8106,97 |